РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

28.12.2022 ел №155

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашу өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 16 августындагы 108 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 16 августындагы 108 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашу өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү тәртибе турындагы нигезләмәнең 1 пунктында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халыкның куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Чирмешән муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов